**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2025 № 221

**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»24.09.2021 ел, № 737 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 24.09.2021 № 737 карары белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
«13) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә урнаштырылган";

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**